**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШЕШМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Комарова, д.14, с.Шешминская Крепость,
423104

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ШЕШМИНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Комаров урамы, 14 йорты, Шешминка Крепосте
авылы, 423104

ИНН 1640003989 тел./факс(84396) 2-36-54 email: Shesh.Cmn2@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.11.2022 ел № 11

Муниципаль учреждениеләрне булдыру, үзгәртеп кору һәм бетерү, гамәлдәге муниципаль учреждениеләрнең төрен үзгәртү, шулай ук аларның уставларын раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль закон, «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 12.01.1996 № 7-ФЗ Федераль закон, «Автоном учреждениеләр турында» 03.11.2006 № 174-ФЗ Федераль закон, «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.05.2010 ел № 83-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль учреждениеләрне булдыру, үзгәртеп кору һәм бетерү, гамәлдәге муниципаль учреждениеләрнең төрен үзгәртү, шулай ук аларның уставларын раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен расларга (кушымта).

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (Pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе

М.Д.Шәйхетдинов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге
Башкарма комитеты карарына
кушымта

«17» ноябрь 2022 ел № 10

**Муниципаль учреждениеләрне булдыру, үзгәртеп кору һәм бетерү, гамәлдәге муниципаль учреждениеләрнең төрен үзгәртү, шулай ук аларның уставларын раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү ТӘРТИБЕ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 12.01.1996 ел, № 7-ФЗ Федераль закон, «Автономияле оешмалар турында» 03.11.2006 ел, № 174-ФЗ Федераль закон, «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.05.2010 ел, № 83-ФЗ Федераль закон нигезендә эшләнгән әлеге тәртип муниципаль бюджет һәм казна учреждениеләрен төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү, гамәлдәге муниципаль учреждениеләрнең, шул исәптән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты милкендәге мөлкәт базасында төзелгән (төзергә планлаштырыла торган) автоном учреждениеләрнең (алга таба - муниципаль учреждениеләр) төрләрен үзгәртү, шулай ук муниципаль учреждениеләр уставларын раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү процедураларын билгели, әгәр Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларында башкасы каралмаган булса.

2. Муниципаль учреждениеләр социаль, хәйрия, мәдәни, мәгариф, фәнни һәм идарә максатларына ирешү өчен, гражданнарның сәламәтлеген саклау, физик культураны һәм спортны үстерү, гражданнарның рухи һәм башка матди булмаган ихтыяҗларын канәгатьләндерү, гражданнарның һәм оешмаларның хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен яклау, бәхәсләрне һәм конфликтларны чишү, юридик ярдәм күрсәтү максатларында, шулай ук иҗтимагый иминлекләргә ирешүгә юнәлтелгән башка максатларда оештырылырга мөмкин.

Бюджет учреждениесе дип Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба – авыл җирлеге) тарафыннан фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль яклау, халыкны эш белән тәэмин итү, физик культура һәм спорт өлкәләрендә, шулай ук башка өлкәләрдә җирле үзидарә органнарының Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өчен төзелгән коммерциячел булмаган оешма танылa.

Казна учреждениесе - муниципаль хезмәтләр күрсәтүне, эшләр башкаруны һәм (яисә) муниципаль функцияләрне җирле үзидарә органнарының Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында үтәүне гамәлгә ашыручы муниципаль учреждение, аның эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү бюджет сметасы нигезендә шәһәр округы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Автоном учреждение - муниципаль берәмлек тарафыннан фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, массакүләм мәгълүмат чаралары, социаль яклау, халыкны эш белән тәэмин итү, физик культура һәм спорт өлкәләрендә, шулай ук федераль законнарда билгеләнгән очракларда башка өлкәләрдә (шул исәптән балалар һәм яшьләр белән күрсәтелгән өлкәләрдә чаралар үткәргәндә) Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру

максатларында эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өчен булдырылган коммерциячел булмаган оешма.



3. Муниципаль учреждениеләр милкен гамәлгә куючы һәм милекче булып Башкарма комитет тора (алга таба - гамәлгә куючы, милекче).

4. Авыл җирлеге исеменнән муниципаль учреждениенең гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен һәм муниципаль учреждение мөлкәтенең милекче хокукларын Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) башкара. Муниципаль учреждение эшчәнлеген координацияләү, җайга салу һәм контрольдә тоту бурычлары башкарма комитетка йөкләнә.

5. Муниципаль учреждениегә милекче тарафыннан беркетелгән һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка нигезләр буенча муниципаль учреждение сатып алган мөлкәткә муниципаль учреждение оператив идарә хокукын ала. Муниципаль учреждениенең керем китерә торган эшчәнлегеннән кергән табышлар исәбенә муниципаль учреждение мөлкәтне сатып алырга хокуклы.

6. Бюджет учреждениесе үз йөкләмәләре буенча үзендә оператив идарә итү хокукында булган барлык мөлкәт белән, шул исәптән керем китерүче эшчәнлектән алынган керемнәр хисабына сатып алынганы белән җавап бирә, бюджет учреждениесенә әлеге мөлкәтнең милекчесе тарафыннан беркетелгән яисә бюджет учреждениесе тарафыннан милекче бүлеп биргән акчалар хисабына сатып алынган аеруча кыйммәтле күчмә милектән тыш, шулай ук аның нинди нигезләр буенча бюджет учреждениесенең оператив идарәсенә керүенә һәм нинди акчалар хисабына сатып алынуына карамастан күчемсез милектән тыш.

7. Гражданнарга зыян китерүгә бәйле бюджет учреждениесе йөкләмәләре буенча әлеге Тәртипнең 6 пункты нигезендә түләтү юнәлтелергә мөмкин учреждениенең мөлкәте җитәрлек булмаганда, бюджет учреждениесе милекчесе субсидиар җаваплылык тота.

8. Казна учреждениесе үз йөкләмәләре буенча аның карамагындагы акчалар белән җавап бирә. Акчалар җитмәсә, казна учреждениесе йөкләмәләре буенча субсидиар җаваплылыкны аның милекчесе йөртә.

9. Автоном учреждение үз йөкләмәләре буенча күчемсез милектән һәм гамәлгә куючы тарафыннан аңа беркетелгән яки әлеге мөлкәтне сатып алуга гамәлгә куючы белән бирелгән чаралар хисабына автоном учреждение тарафыннан сатып алынган аеруча мөһим күчмә мөлкәттән тыш, оператив идарә итү хокукында булган мөлкәте белән җавап бирә.

10. Муниципаль учреждениеләр үз мөлкәтләре милекчеләре йөкләмәләре буенча җавап бирми.

## II. Муниципаль учреждение төзү

11. Муниципаль бюджет яисә казна учреждениесе әлеге бүлек нигезендә аны гамәлгә кую, шул ук хокукый формадагы башка муниципаль бюджет яисә казна учреждениесен үзгәртеп кору һәм Россия Федерациясе Федераль законнарында каралган очракларда, башка оештыру-хокукый формадагы юридик затны үзгәртү рәвешендә үзгәртеп кору нәтиҗәсендә, шулай ук гамәлдәге муниципаль учреждениенең типын әлеге Тәртипнең VII бүлеге нигезендә үзгәртү юлы белән төзелә ала.

Муниципаль учреждениене оештыру, үзгәртеп кору яки бетерү инициаторы булып Башкарма комитет, гамәлдәге муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре тора.

12. Муниципаль учреждениене төзү турындагы карар аның учреждениесе юлы белән Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан карар рәвешендә кабул ителә.

13. Муниципаль учреждение төзү турында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитетының карарында (алга таба - Башкарма комитет карары) булырга тиеш:

- төзелә торган муниципаль учреждениенең исеме, аның типын күрсәтеп;
- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, Чирмешән муниципаль районының муниципаль хокукый актлары нигезендә билгеләнгән төзелә торган муниципаль учреждение эшчәнлегенең төп максатлары;
- төзелә торган муниципаль учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырачак Шешминка авыл җирлеге җирле үзидарә органы исеме;
- хезмәткәрләрнең иң чик штат саны;

- муниципаль учреждение уставының раслана торган проекты;
- муниципаль учреждение җитәкчесен билгеләү турында карар;



- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитетының вәкаләтле затларына йә бюджет учреждениесе җитәкчесенә төзелгән муниципаль учреждениене дәүләт теркәвенә алу өчен кирәкле гамәлләр кылу турында йөкләмәләр.

14. Муниципаль учреждение төзү һәм аның уставын раслау турында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты карары проекты Чирмешән муниципаль районының финанс органы һәм мөлкәт сорауларын күзәтүче Чирмешән муниципаль районы органы белән килештереп тармак структур бүлекчәсе тарафыннан әзерләнә.

15. Яңа төзелә торган муниципаль учреждениеләр уставы әлеге Тәртипнең III бүлеге нигезендә раслана.

16. Муниципаль учреждение «Юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиеш. Муниципаль учреждение юридик зат буларак Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынганнан соң төзелгән дип санала.

## III. Муниципаль учреждение уставын раслау һәм аңа үзгәрешләр кертү

17. Муниципаль учреждение Уставы, шулай ук аңа кертелә торган үзгәрешләр Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән раслана

18. Муниципаль учреждение уставында булырга тиеш:

- муниципаль учреждение атамасын, аның тибына күрсәтүне; муниципаль учреждениенең урнашу урыны турында мәгълүматны; муниципаль учреждениенең гамәлгә куючысы исеме һәм мөлкәт милекчесе турында белешмәне; муниципаль учреждениенең гамәлгә куючысы һәм мөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы шәһәр округының җирле үзидарә органы исемен;
- муниципаль учреждение эшчәнлегенең предметы һәм максатлары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, Чирмешән муниципаль районының муниципаль хокукый актлары нигезендә, шулай ук эшчәнлек төрләренең тулы исемлеге (эшчәнлекнең төп төрләрен һәм эшчәнлекнең төп булмаган башка төрләрен күрсәтеп, шул исәптән түләү өчен гамәлгә ашырылучы һәм керем алып килүче), аларны муниципаль учреждение ирешү өчен булдырылган максатларга туры китереп гамәлгә ашырырга хокуклы;
- муниципаль учреждение эшчәнлеген оештыру һәм идарә итү бүлеге, шул исәптән муниципаль учреждение белән идарә итү органнары структурасы, компетенциясе, аларны формалаштыру тәртибе, мондый органнарның вәкаләтләр сроклары һәм эшчәнлек тәртибе турында мәгълүматларны үз эченә алган, шулай ук учреждение җитәкчесенең җаваплылыгы, хокуклары һәм бурычлары турындагы нигезләмә;
- муниципаль учреждениене финанс яктан тәэмин итү һәм мөлкәт турында бүлек, үз эченә шул исәптән алган:
- муниципаль учреждение мөлкәтен формалаштыру чыганаклары;
- муниципаль учреждение сатып алган мөлкәт белән эш итү тәртибе (мондый мөлкәтне сатып алуга милекче тарафыннан учреждениегә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән сатып алынган мөлкәттән тыш);
- зур килешүләрне һәм аларны башкаруда кызыксыну булган килешүләрне гамәлгә ашыру тәртибе;
- муниципаль учреждениегә беркетелгән мөлкәтне яисә әлеге муниципаль учреждениегә шәһәр округы бюджетыннан бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән сатып алынган мөлкәтне читләштерү яки йөкләү мөмкин булган нәтиҗәләргә китерә торган алыш-бирешләрне башкаруны тыю, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача билгеләнмәгән булса;
- муниципаль учреждениегә шәхси счетлар ачу, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль учреждениегә ачыла торган бүтән счетлар турында нигезләмәләр;
- гамәлдәге муниципаль учреждениене бетерү, үзгәртеп кору һәм тибын үзгәртү,

һәм муниципаль учреждение бетерелгән очракта мөлкәттән файдалану тәртибе турында нигезләмәләр;



- муниципаль учреждениенең филиаллары һәм вәкиллекләре турында белешмәләр (булган очракта);
- муниципаль учреждение уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе;
- Россия Федерациясе законнарында каралган башка мәгълүматлар.

19. Гамәлдәге муниципаль учреждение тибын үзгәрткәндә муниципаль учреждение уставында түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

- муниципаль учреждениенең эшчәнлеге характерына, шулай ук аның мөлкәте милекчесенә күрсәтмәне үз эченә алган исеме;
- муниципаль учреждение тибына күрсәтмә;
- муниципаль учреждениенең урнашу урыны;
- муниципаль учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы шәһәр округының җирле үзидарә органы турында белешмәләр;
- муниципаль учреждение эшчәнлегенең предметы һәм максатлары;
- муниципаль учреждение булдырылган максатларга ярашлы рәвештә башкарырга хокуклы эшчәнлек төрләренең тулы исемлеге;
- муниципаль учреждениенең филиаллары, вәкиллекләре турында белешмәләр;
- муниципаль учреждение органнарының структурасы, компетенциясе, аларны формалаштыру тәртибе, вәкаләтләр сроклары һәм мондый органнарның эшчәнлек тәртибе;
- федераль законнарда каралган башка мәгълүматлар.

20. Муниципаль учреждение уставы, муниципаль учреждение уставына кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр яисә муниципаль учреждение уставы яңа редакциядә юридик затларны дәүләт теркәвенә алучы органда «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 08.08.2001 ел, № 129-ФЗ Федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

## IV. Муниципаль учреждениегә беркетелә торган мөлкәт составын билгеләү тәртибе

21. Муниципаль учреждение мөлкәтен акчалата һәм башка рәвешләрдә формалаштыру чыганаклары булып тора:

- оештыручыдан регуляр һәм бер тапкыр бирелә торган керемнәр;
- ирекле милек взнослары һәм иганәләр;
- товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатудан кергән табыш;
- муниципаль учреждение милкеннән алына торган керемнәр;
- Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка керемнәр.

22. Муниципаль учреждение милке аңа Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә оператив идарә итү хокукында беркетелә. Милек белән оператив идарә итү хокукы кабул итү – тапшыруның тиешле акты белән рәсмиләштерелгән мөлкәтне факттагы тапшыру вакытыннан барлыкка килә.

23. Муниципаль учреждение тарафыннан үз устав бурычларын үтәү өчен кирәкле җир участогы аңа даими (сроксыз) файдалану хокукында бирелә.

24. Муниципаль учреждение «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Автоном учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләрдә, үз эшчәнлегенең максатлары, әлеге мөлкәтнең билгеләнеше нигезендә милеккә ия, файдалана һәм, күрсәтелгән федераль законнар белән башкача билгеләнмәсә, әлеге мөлкәт белән милекче ризалыгы белән идарә итә, шул исәптән аны шәһәр округы башлыгы билгеләгән тәртиптә гамәлдән чыгаруны гамәлгә ашыра.

25. Бюджет учреждениесе керем китерүче эшчәнлекне ул барлыкка китерелгән максатларга ирешүгә хезмәт итсә генә һәм бу максатларга туры килсә башкарырга хокуклы, әгәр мондый эшчәнлек гамәлгә кую документларында күрсәтелгән булса. Мондый эшчәнлектән алынган керемнәр һәм шулар хисабына сатып алынган мөлкәт бюджет учреждениесенең мөстәкыйль идарәсенә керә.

26. Казна учреждениесе үз оештыру документлары нигезендә керем китерүче эшчәнлекне башкара ала. Әлеге эшчәнлектән алынган керемнәр шәһәр округы бюджетына

керә.

27. Бюджет учреждениесе җитәкчесе бюджет учреждениесе алдында, Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозып, эре алыш-биреш ясап, бюджет учреждениесенә салынган зыяннар күләмендә җаваплылык тота, бу килешү дөрес түгел дип танылганга карамастан.

28. Бюджет учреждениеләре акча чараларын кредит оешмаларында депозитларга урнаштырырга, шулай ук Россия Федерациясе федераль законнарында башкасы каралмаган булса, кыйммәтле кәгазьләр белән килешүләр төзергә хокуклы түгел.

29. Гамәлгә куючы рөхсәтеннән күчемсез милекне яисә гамәлгә куючы тарафыннан бюджет учреждениесенә беркетелгән яки мондый мөлкәтне сатып алуга аңа гамәлгә куючы тарафыннан бүлеп бирелгән чаралар исәбенә бюджет учреждениесы тарафыннан сатып алынган аеруча кыйммәтле күчмә мөлкәтне арендага бирү очрагында, гамәлгә куючы тарафыннан мондый мөлкәтне карап тотуга финанс белән тәэмин итү гамәлгә ашырылмый.

30. Милекче муниципаль учреждениегә беркетелгән яки муниципаль учреждение тарафыннан әлеге мөлкәтне сатып алуга милекче тарафыннан бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән сатып алынган артык, кулланылмый торган яки билгеләнеше буенча файдаланылмый торган мөлкәтне алырга хокуклы. Муниципаль учреждениедән алынган мөлкәтне милекче үз теләге белән кулланырга хокуклы.

## V. Муниципаль учреждениеләр белән идарә итү

31. Муниципаль учреждение үз эшчәнлеген Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Федераль законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, Чирмешән муниципаль районының муниципаль хокукый актлары һәм муниципаль учреждение уставы нигезендә билгеләнгән эшчәнлек максатлары һәм предметы нигезендә гамәлгә ашыра.

32. Муниципаль учреждение белән идарә итү өлкәсендә гамәлгә куючының аерым компетенциясенә керә:

- муниципаль учреждение эшчәнлегенең максатын һәм төп төрләрен билгеләү;
- муниципаль учреждение уставын раслау һәм/яки Уставка үзгәрешләр/өстәмәләр кертү;
- муниципаль учреждение филиалларын булдыруга һәм бетерүгә, аның вәкиллекләрен ачуга һәм ябуга ризалык бирә;
- муниципаль учреждение җитәкчесен билгеләү һәм аның вәкаләтләрен туктату, шулай ук аның белән хезмәт килешүен төзү һәм туктату, әгәр дә тиешле эшчәнлек өлкәсендәге оешмалар өчен федераль законнар белән җитәкчене билгеләү һәм аның вәкаләтләрен туктату һәм (яисә) аның белән хезмәт килешүен төзү һәм туктату тәртибе каралмаган булса;
- җитәкченең хезмәт окладына өстәмәләр һәм өстәмә түләү билгеләү;
- җитәкчегә стимуллаштыручы характердагы түләүләрне билгеләү (шул исәптән премия бирү) ;
- хезмәт өчен түләү турындагы һәм муниципаль учреждение җитәкчесен премияләү тәртибе турындагы нигезләмәләрне раслау һәм хезмәт өчен түләү турындагы һәм муниципаль учреждение хезмәткәрләрен премияләү тәртибе турында нигезләмәне килештерү;
- муниципаль учреждение җитәкчесенә дисциплинар җәза бирү, аны бүләкләү;
- муниципаль учреждениенең иң чик штат санын раслау һәм штат расписаниесен килештерү;
- муниципаль учреждение эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү;
- муниципаль учреждение җитәкчесен хезмәт командировкаларына җибәрү;
- бюджет сметасын (казна учреждениесе өчен), муниципаль заданиене (бюджет учреждениесе өчен) раслау;
- муниципаль учреждениене үзгәртеп корганда тапшыру актын яки бүлү балансын раслау;
- бетерү комиссиясен билгеләү һәм арадаш бетерү һәм бетерү балансларын раслау;
- муниципаль учреждениегә муниципаль милекне оператив идарәгә тапшыру, аның сакланышын һәм устав максатларына һәм муниципаль учреждение эшчәнлегенең

төрләренә ярашлы рәвештә кулланылышын тикшереп тору;

- муниципаль учреждениенең оператив идарәсеннән муниципаль милекне алу; 
- муниципаль учреждениене үзгәртеп кору һәм/яки бетерү, шулай ук аның тибындагы үзгәреш турында тәкъдимнәрне карау һәм карарлар кабул итү;
- Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда зур килешүләр, башкарылуында кызыксыну булган килешүләрне һәм башка килешүләрне башкару очракларын килештерү;
- муниципаль учреждениенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын төзү һәм раслау тәртибен билгеләү (муниципаль казна учреждениесеннән тыш);
- Россия Федерациясе законнарында каралган башка мәсьәләләрне хәл итү.

33. Муниципаль учреждение җитәкчесе компетенциясенә, Россия Федерациясе законнары яисә әлеге Тәртип белән гамәлгә куючы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрдән тыш, муниципаль учреждение эшчәнлегенә агымдагы җитәкчелек итүне башкару мәсьәләләре керә.

34. Муниципаль учреждение җитәкчесе үз эшчәнлегендә гамәлгә куючы каршында хисап тота.

35. Муниципаль учреждение җитәкчесе вәкаләтләре:

- хезмәт килешүен гамәлгә куючы белән төзелгән шартнамә нигезендә үз эшчәнлеген башкара;
- муниципаль учреждение исеменнән ышанычнамәсез эш итә, Чирмешән муниципаль районының Шешминка авыл җирлеге территориясендә һәм аннан читтә аның мәнфәгатьләрен кайгырта, алыш-бирешләр ясый;
- гамәлгә куючы белән килештерү буенча штат расписаниесен, муниципаль учреждениенең еллык бухгалтер хисабын, муниципаль учреждение эшчәнлеген регламентлаучы эчке документларны раслый, муниципаль учреждение кысаларында гамәлдә булган боерыкларны чыгара;
- хезмәткәрләрне вазифага билгели һәм вазифадан азат итә, алар белән хезмәт килешүләре төзи;
- муниципаль учреждение хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләрен раслый;
- муниципаль учреждение хезмәткәрләренә түләү тәртибе турындагы һәм премияләү тәртибе турындагы нигезләмәне гамәлгә куючы белән килештереп раслый;
- хезмәт өчен бүләкләүләр куллана, муниципаль учреждение хезмәткәрләренә карата дисциплинар җәзаларны кабул итә һәм кире ала;
- бухгалтерлык исәбенең торышы, хисапны, шул исәптән бухгалтерлык һәм статистика буенча вакытында тапшыру һәм тулылыгы өчен җаваплылык тота;
- «Коррупциягә каршы көрәш турында»25.12.2008 ел, № 273-ФЗ Федераль законның 13.3 статьясы нигезендә коррупцияне кисәтү чараларын тормышка ашыра;
- муниципаль учреждение уставыннан һәм хезмәт шартнамәсеннән килеп чыга торган, Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган башка функцияләрне башкара.

36. Муниципаль учреждение җитәкчесе Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль учреждениегә аның гаепле гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында китерелгән зыяннар өчен, шул исәптән муниципаль учреждение мөлкәтен югалткан очракта да җавап бирә.

## VI. Муниципаль учреждениене үзгәртеп кору

37. Муниципаль учреждениене үзгәртеп кору берләштерү, тоташтыру, бүлү, бүленеп чыгу һәм үзгәртү рәвешендә башкарылырга мөмкин.

38. Муниципаль учреждениене берләштерү, тоташтыру, бүлү, бүленеп чыгу һәм үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп кору турындагы карар муниципаль учреждениене гамәлгә кую юлы белән охшаш тәртиптә кабул ителә.

39. Күрсәтелгән карар үз эченә алырга тиеш:

- үзгәртеп кору процессында катнашучы муниципаль учреждениеләрнең исеме, аларның төрләрен күрсәтеп;
- үзгәртеп кору формасы;
- үзгәртеп кору процессы тәмамланганнан соң муниципаль учреждение (учреждениеләр) исеме;

- үзгәртеп корыла торган муниципаль учреждениене (учреждениеләрне) гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Ульяновка авыл җирлеге җирле үзидарә органының (органнарының) исеме;
- үзгәртеп корыла торган муниципаль учреждение (учреждениеләр) эшчәнлегенең төп максатларын үзгәртү (саклау) турында мәгълүмат;
- иң чик штат санын үзгәртү (саклау) турында мәгълүмат;
- муниципаль учреждениене үзгәртеп кору чаралары исемлеге уздыру срокларын күрсәтеп.

40. Муниципаль учреждениеләрнең кушылуы булып, яңа муниципаль учреждение төзү һәм аңа ике яки берничә муниципаль учреждениенең хокуклары һәм бурычлары күчү һәм соңгыларның эшчәнлеген туктату танылa.

Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе яисә башка вәкаләтле зат тапшыру актын раслый, яңа барлыкка килгән муниципаль учреждение уставын раслый һәм аның җитәкчесен билгели.

Муниципаль учреждениеләрне берләштергәндә аларның һәркайсының хокуклары һәм бурычлары тапшыру акты нигезендә яңа барлыкка килгән муниципаль учреждениегә күчә.

41. Муниципаль учреждениегә кушылу дип хокуклары һәм вазыйфалары кушылу гамәлгә ашырыла торган муниципаль учреждениегә күчүе белән бер яки берничә муниципаль учреждениенең туктатылуы танылa.

Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе яисә башка вәкаләтле зат тапшыру актын раслый, Ульяновка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе муниципаль учреждение уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләрне раслый һәм кирәк булганда әлеге муниципаль учреждение җитәкчесен билгели.

Бер яки берничә муниципаль учреждениене икенче муниципаль учреждениегә кушканда, тапшыру акты нигезендә, кушылган муниципаль учреждениеләрнең хокуклары һәм бурычлары соңгысына күчә.

42. Муниципаль учреждениеләрнең бүленеше дип муниципаль учреждениенең туктатылуы яңа төзелгән муниципаль учреждениеләргә хокуклары һәм бурычлары күчүе белән танылa.

Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе яисә ул вәкаләт биргән башка зат аеру балансын раслый, яңа төзелгән муниципаль учреждениеләр уставларын раслый һәм аларның җитәкчеләрен билгели.

Муниципаль учреждениене бүлгәндә аның хокуклары һәм бурычлары аеру балансы нигезендә яңа төзелгән муниципаль учреждениеләргә күчә.

43. Муниципаль учреждениедән бүленеп чыгу дип бер яки берничә муниципаль учреждение булдыру танылa, аларның һәрберсенә үзгәртеп корылган муниципаль учреждение хокуклары һәм бурычлары өлеше соңгысын туктатмыйча гына күчә.

Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе яисә башка вәкаләтле зат бүлем балансын раслый, яңа төзелгән муниципаль учреждениеләр уставларын раслый һәм аларның җитәкчеләрен билгели, шулай ук үзгәртеп корылган муниципаль учреждение уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләрне раслый һәм кирәк булганда аның җитәкчесен билгели.

44. Муниципаль учреждениеләрне башка рәвештәге коммерцияле булмаган оешмаларга яисә хуҗалык җәмгыятенә әверелдерү «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 12.01.1996 елдагы 7-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә рөхсәт ителә.

Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе яисә башка вәкаләтле зат тапшыру актын раслый, яңа оешкан оешманың уставын раслый һәм аның җитәкчесен билгели.

Муниципаль учреждениене үзгәртеп корганда яңа оешкан оешмага тапшыру акты нигезендә үзгәртеп корылган муниципаль учреждениенең хокуклары һәм бурычлары күчә.

45. Муниципаль учреждениене үзгәртеп кору турында карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә ул юридик затларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы вәкаләтле дәүләт органына үзгәртеп кору процедурасы башлану турында үзгәртеп кору төрен күрсәтеп язмача хәбәр итәргә тиеш.

46. Үзгәртеп корыла торган муниципаль учреждение юридик затларның бердәм дәүләт реестрына үзгәртеп кору процедурасын башлау турында язманы керткәннән соң айга бер тапкыр ешлыгы белән ике тапкыр "Вестник государственной регистрации" журналында үзен үзгәртеп корулары турында хәбәрнамә бастырып чыгара.

47. Казна учреждениесен үзгәртеп корганда, кредитор вакытыннан алда тиешле йөкләмәләрне үтәүне, шулай ук йөкләмәләрне һәм аңа бәйле зыяннарны каплауны таләп итәргә хокуклы түгел.

48. Муниципаль учреждениеләрне үзгәртеп коруга бәйле рәвештә Уставка кертелә торган үзгәрешләр әлеге Тәртипнең III бүлеге нигезендә раслана.

49. Аның карамагындагы муниципаль учреждениеләр тарафыннан күрсәтелергә тиешле муниципаль хезмәтләр (эшләр) күләмен саклап калганда, муниципаль учреждениены (учреждениеләрне) үзгәртеп кору турында карар кабул итү, чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр округы администрациясе органына муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) шәһәр округы бюджеты акчаларын баш бүлүче (бүлүче) буларак бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмен киметү өчен нигез була алмый.

50. Яңа барлыкка килгән оешма (оешмалар) дәүләт теркәвенә алынганнан бирле, кушылу рәвешендә үзгәртеп кору очракларыннан тыш, муниципаль учреждение үзгәртеп корылган дип санала.

Муниципаль учреждениене аңа башка оешманы кушу рәвешендә үзгәртеп корганда, аларның беренчесе юридик затларның бердәм дәүләт реестрына тоташтырылган оешма эшчәнлеген туктату турындагы язуны керткәннән бирле үзгәртеп корылган дип санала.

51. Үзгәртеп кору нәтиҗәсендә яңадан барлыкка килгән оешманы (оешмаларны) дәүләт теркәвенә алу һәм юридик затларның бердәм дәүләт реестрына үзгәртеп корылган муниципаль учреждение (муниципаль учреждениеләр) эшчәнлеген туктату турында язмалар кертү «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 08.08.2001 ел, № 129-ФЗ Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

52. Үзгәртеп корылган муниципаль учреждениеләр, дәүләт теркәвенә алынганнан соң ун көн эчендә мөлкәт мәсьәләләрен алып баручы Чирмешән муниципаль районы органына һәм тиешле тармакны кураторлаучы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты урынбасарына үзгәртеп корыла торган муниципаль учреждениеләргә карата теркәү эшләре турында кирәкле мәгълүматны тапшыралар.

## VII. Муниципаль учреждение тибын үзгәртү

53. Гамәлдәге муниципаль учреждение төрен үзгәртү аны үзгәртеп кору дип саналмый.

Гамәлдәге муниципаль учреждение тибын үзгәрткәндә аның уставына әлеге Тәртипнең Ш бүлеге нигезендә тиешле үзгәрешләр кертелә.

54. Гамәлдәге муниципаль учреждение тибын үзгәртү турында карар тармак структур бүлекчәсе яки муниципаль учреждение җитәкчесе инициативасы буенча карар (постановление) рәвешендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан кабул ителә. Гамәлдәге муниципаль учреждение тибын үзгәртү юлы белән автоном учреждение төзегәндә мондый учреждение тибын үзгәртү турында карар муниципаль учреждение ризалыгы белән кабул ителә.

Бюджет яисә казна учреждениесе автоном учреждениене гамәлгә куючы карары буенча муниципаль милектәге мөлкәт базасында төзелгән автоном учреждениеләргә карата әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән тәртиптә аның тибын үзгәртү юлы белән төзелә ала.

55. Муниципаль бюджет яисә казна учреждениесен төзү максатыннан Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитетының гамәлдәге муниципаль учреждение тибын үзгәртү турында карары үз эченә алырга тиеш:

- гамәлдәге муниципаль учреждениенең исеме, аның тибын күрсәтеп;
- төзелә торган муниципаль учреждениенең исеме, аның тибын күрсәтеп;
- төзелә торган муниципаль учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органының исеме;
- муниципаль учреждение эшчәнлегенең төп максатларын үзгәртү (саклау) турында мәгълүмат;
- иң чик штат санын үзгәртү (саклау) турында мәгълүмат;
- типны үзгәртү юлы белән муниципаль учреждение булдыру буенча чаралар исемлеге.

56. Гамәлдәге муниципаль учреждение тибын үзгәртү юлы белән автоном учреждение булдыру турындагы карарда булырга тиеш:

-  автоном учреждениегә беркетелә торган мөлкәт турында белешмәләр, шул исәптән күчемсез милек объектлары һәм аеруча кыйммәтле күчмә милек исемлеге;



-  төзелә торган муниципаль учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органының исеме;

-  әлеге чараларны уздыру вакытын һәм җаваплы кешене күрсәтеп, автоном учреждение төзү буенча чаралар исемлеге.

57. Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитетының гамәлдәге муниципаль учреждение тибын үзгәртү һәм гамәлдәге муниципаль учреждение тибын үзгәртү юлы белән автоном учреждение булдыру турындагы карары проекты Чирмешән муниципаль районының финанс органы һәм мөлкәт сораулары белән идарә итүче Чирмешән муниципаль районы органы белән килештереп тармак структур бүлекчәсе тарафыннан әзерләнә.

58. Үзгәртелгән типтагы учреждение тарафыннан күрсәтелергә (башкарылырга) тиешле муниципаль хезмәтләр (эшләр) күләмен саклап калганда гамәлдәге муниципаль учреждениеның типын үзгәртүнең максатка ярашлылыгы турында карар кабул итү, хезмәт күрсәтүгә (башкаруга) Чирмешән муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүче (бүлүче) буларак Чирмешән муниципаль районы финанс органына бүлеп бирелә торган чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет ассигнованиеләре күләмен киметү өчен нигез була алмый.

## VIII. Муниципаль учреждениеләрне бетерү

59. Муниципаль учреждение түбәндәге очракларда бетерелергә мөмкин:

-  Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты карары буенча;

-  суд карары буенча Россия Федерациясе Граждан кодексы һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән нигезләр буенча һәм тәртиптә.

60. Муниципаль учреждениене бетерү аның эшчәнлеген бүтән затларга хокукый дәвамчанлык тәртибендә хокук һәм бурычлар күчмичә туктатуга китерә.

61. Муниципаль учреждениене бетерү турында карар кабул ителгән очракта Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе яисә муниципаль учреждениене бетерү турында карар кабул иткән орган ликвидация комиссиясен билгели, Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль учреждениене бетерү тәртибен һәм срокларын билгели.

Тармак структур бүлекчәсе муниципаль учреждениене бетерү турында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитетының тиешле карар проектын әзерли.

62. Бетерү комиссиясе билгеләнгәннән бирле аңа муниципаль учреждение эшләре белән идарә итү вәкаләтләре күчә. Ликвидацияләү комиссиясе бетерелә торган муниципаль учреждение исеменнән судта чыгыш ясый.

63. Ликвидацияләү комиссиясе юридик затларны дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар бастырыла торган матбугат органнарында муниципаль учреждениене бетерү, аның кредиторлары тарафыннан таләпләрне белдерү тәртибе һәм срогы турында басмалар урнаштыра. Кредиторлары тарафыннан таләпләрне белдерү срогы муниципаль учреждениене бетерү турында бастырылган көннән ике айдан да ким була алмый.

64. Ликвидацияләү комиссиясе кредиторларны ачыклау һәм дебиторлык бурычларын алу буенча чаралар күрә, шулай ук кредиторларга муниципаль учреждениене бетерү турында язма рәвештә хәбәр итә.

Муниципаль казна учреждениесен бетергәндә, кредитор вакытыннан алда тиешле йөкләмәне үтәүне, шулай ук йөкләмәне туктатуны һәм аңа бәйле зыяннарны каплауны таләп итәргә хокуклы түгел.

65. Кредиторлар тарафыннан таләпләр кую срогы тәмамлангач, ликвидацияләү комиссиясе арадаш бетерү балансын төзи, анда бетерелә торган муниципаль учреждение мөлкәте составы, кредиторлар тарафыннан куелган таләпләр исемлеге, шулай ук аларны карау нәтиҗәләре турында белешмәләр бар.

Арадаш ликвидацияләү балансы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе йә Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан аңа Башкарма комитет мондый вәкаләтләрне йөкләнгән орган, йә аны бетерү турында карар кабул иткән орган тарафыннан раслана.

66. Әгәр дә бетерелә торган муниципаль учреждениедә акчалар кредиторларның таләпләрен канәгатьләндерү өчен җитмәсә, ликвидацияләү комиссиясе муниципаль учреждение милкен җәмәгать сатуларыннан суд карарларын үтәү өчен билгеләнгән тәртиптә сата.

67. Бетерелә торган муниципаль учреждение кредиторларына акчалата суммаларны түләү Россия Федерациясе Граждан кодексында билгеләнгән чиратлылык тәртибендә, аны раслаган көннән башлап, арадаш ликвидацияләү балансы нигезендә ликвидацияләү комиссиясе тарафыннан башкарыла, түләүләр арадаш ликвидацияләү балансы расланган көннән ай узганнан соң башкарыла торган өченче һәм дүртенче чират кредиторларыннан тыш.

68. Кредиторлар белән исәп-хисап ясаганнан соң ликвидацияләү комиссиясе ликвидация балансын төзи, ул Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе йә Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан мондый вәкаләтләр йөкләнгән орган, йә аны бетерү турында карар кабул иткән орган тарафыннан раслана.

69. Кредиторларның таләпләрен канәгатьләндергәннән соң калган муниципаль учреждение мөлкәте, шулай ук муниципаль учреждение йөкләмәләре буенча түләтү федераль законнар нигезендә юнәлдерелә алмаган мөлкәт ликвидацияләү комиссиясе тарафыннан мөлкәт иясенә тапшырыла.

70. Муниципаль учреждениене бетерү тәгәлләнгән дип санала, ә муниципаль учреждение - эшләүдән туктаган дип, бу хакта язма юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелгәннән соң.